**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.39, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урамы, 39 йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

18 декабрь 2023 ел № 114

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 27 июнендәге № 94 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы № 25-ФЗ, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ Федераль законнарга, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге № 50-ТРЗ, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге № 99-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 27 июнендәге № 94 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4.12. Класс чинын бирү көне дип класс чинын бирү турында карар кабул ителгән көн санала».

1.2.4.19 пунктын төшереп калдырырга.

1.3. 4.21 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәргә сыйныф чины бирү турында карар, әлеге Нигезләмәнең 4.15 сендә күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән сыйныф чины бирү турында тәкъдим органга яки җирле үзидарәнең сыйныф чинын бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш».

1.4.2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Ф.П. Андреев